**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ ЧУКМАРЛИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ**
**БЕРӘМЛЕГЕ**

---

РЕШЕНИЕ | КАРАР

25 нче март 2024 ел | №3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Советның 26.11.2021 ел, № 14 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» РФ Хөкүмәтенең 05.02.2024 № 124 карарына, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 № 248-ФЗ (ред. 25.12.2023) Федераль Законына, Сарман муниципаль районының «Чукмарлы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставына нигезләнеп, Чукмарлы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Советның 26.11.2021 ел, № 14 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пункт) 1.7 пункттан соң «(шул исәптән торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сәнәгать районнары), «Набережная,»сүзе белән тулыландырырга;

1 нче кушымтаның 2 нче пункты чыгарылсын.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Чукмарлы авыл җирлеге
Советы рәисе | И.Х.Хадиуллин